ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

№ 1026 17.12.2018

***Постановление*** ***Карар***

«Чистай муниципаль районында
балаларның һәм яшьләрнең
ялын оештыру турында»

Балалыкны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен тиешле шартлар булдыру максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 19 ноябрендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 07.02.2014 елгы “2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү” дәүләт программасын раслау турында”гы 73 нче Карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 1006 нчы Карары нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тәкъдим ителгәннәрне расларга:

Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турындагы Нигезләмә (1нче кушымта).

Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия турындагы Нигезләмә (2нче кушымта).

Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составы (3нче кушымта).

Балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтлеген һәм мәшгульлеген оештыру буенча ведомствоара комиссиянең эш планы (4нче кушымта).

2. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының бүлекләр начальникларына, шулай ук шәһәр оешмалары һәм учреждениеләре, яшьләр, балалар җәмәгать оешмалары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

халыкны социаль яклау чаралары турындагы мәгълүматны, бигрәк тә ял итү оешмаларында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен юлламалар бирү турындагы мәгълүматны социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмати системасына (алга таба – ЕГИССО) бирү буенча җаваплы органнарны билгеләргә;

балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру системасын саклау буенча чаралар күрергә;

тәэмин итәргә:

ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны; инвалид балаларны; сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, ягъни физик һәм психик үсешендә кимчелекләр булган балаларны; кораллы һәм милләтара конфликтлар, экологик һәм техноген катастрофалар, стихияле бәхетсезлекләр корбаннары булган балаларны; качаклар һәм мәҗбүри күчеп кайтучылар гаиләләрендәге балаларны; экстремаль шартларда калган балаларны; көчләү корбаннары булган балаларны; тәрбияләү колонияләрендә иректән мәхрүм ителеп, җәза срогы узучы балаларны; тәрбияләүнең, белем бирүнең аерым шартларына һәм махсус һәм педагогик якын килүне таләп итүгә мохтаҗ булган, девиантлы (җәмгыять өчен куркыныч) тәртипле гомуми белем бирүче оешмаларда булган балаларны; килеп туган шартлар нәтиҗәсендә тормыш эшчәнлеге объектив төстә бозылган һәм мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәме белән әлеге хәлләрне җиңә алмаучы балаларны; җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән ким булган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 17 декабрендә кабул ителгән “Татарстан Республиксында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы 542 нче номерлы Карары белән билгеләнгән тәртиптә балага айлык пособие алучы гаиләләрдәге балаларны; социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ булган балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүчеләрне; социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларны (алга таба – авыр тормыш хәлендә калган балалар);

чакырылыш комиссияләре тәкъдимнәре буенча һәм медицина күрсәткечләрен исәпкә алып, шул исәптән укучы балаларның каникул вакытларында ялын оештыруны гамәлгә ашыручы, мәгариф оешмалары тарафыннан оештырылган лагерьларда армиягә чакырылу яшенә җитмәгән егетләрнең ялын оештыру буенча;

социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге иң күп сандагы балаларның ялын оештыру өчен шартлар;

**Чистай муниципаль районында балалар һәм яшьләр ял итүче коммерцияви булмаган оешмалар территорияләрен тәүлек әйләнәсе саклау, җәмәгать тәртибе һәм иминлек;**

балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән санитар-эпидемиологик, хокук тәртибе, санитар-экологик һәм янгын куркынычсызлыгы иминлеге, балаларның суда ял иткәндәге иминлеге һәм ял итү урыннарында аларны сәламәтләндерү буенча чаралар комплексын эшләү һәм үткәрү;

һәр смена ачылыр алдыннан балаларның ялын оештыруның аларның янгын иминлеге таләпләренә, санитар кагыйдәләргә, суда кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләренә, хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау торышы, ял итүчеләрнең иминлеге шартларына туры килүен тикшерү максатында

комплекслы тикшерү оештыру, торак корпусларның, туклану блокларының, лагерьны су белән тәэмин итү чыганакларының санитар торышына, мунча-кер юуу комплексларының торышына, электр җиһазларының торышына, янгын автоматикасының, кешеләргә янгын турында хәбәр итү системасының, телефон элемтәсенең, янгын сүндерүнең беренчел чараларының булу-булмавы һәм төзеклегенә, персоналның янгын иминлеге кагыйдәләрен белүен тикшерүгә аерым игътибар биреп;

балаларның ял итү оешмасын аларның гамәлдәге санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килүен раслаучы дәүләт-санитар эпидемиологик күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән документлар булганда ачу, шулай ук лагерьларның матди-техник торышын ныгытуга юнәлдерелгән, янгын иминлеге бозуларны бетерү буенча күрсәтмәләрне тулы күләмдә һәм санитария законнарын бозулар буенча күрсәтмәләрне үтәгәндә;

балаларның ял итү оешмаларының санитар кагыйдәләрне үтәве һәм лаборатор-инструменталь тикшеренүләр уздыруга билгеләнгән тәртиптә аккредитация алган лабораторияләр белән килешүләр төзеп, санитар-эпидемиягә каршы (кисәтү) чарараларны үтәп;

ял оешмаларына кабул ителгән балалар турындагы медицина документларында профилактик прививкаларның милли календаре нигезендә йогышлы авыруларга каршы прививка ясату турында, яшәү, тәрбияләнү, уку урыннары буенча йогышлы авырулар белән авыраучылар белән элемтәләр булмавы турындагы, туберкулин диагностикалау, флюроографик тикшеренү (15 яшьтән узган яшүсмерләр өчен), гельминтологик һәм эчәк авырулары булмау, йогышлы тире авырулары, шул исәптән бет булмау турында белешмә булу;

урман техник чаралар уздыру (кыска булып үсүче агачларны, корыган ботакларны, куакларны кисү, яшь үсентеләрне кисү, үләннәрне чабу, коры-сорыны һәм балаларның ял итү оешмалары территориясеннән чүп-чарны чыгару), ялны оештыру буенча бөтен кампания буенча һәм кирәк булганда коры-сорыны һәм чүп-чарны чыгару лагерь тирәли 500 метрлы радиуста талпанга һәм бөҗәкләргә каршы эшкәртү үткәрергә;

барлык корылмаларда дератизацион эшкәртүләр уздырырга, шул исәптән файдаланылмый торган, ачык территориядә, ял итү оешмасы тирәли 500 метр радиуста лагерьлар ачылганчы 30-40 көн алдан барьер булдырырга һәм аларны ачканчы 7 көн алдан һәм аларны консервацияләгәндә, ә сменалар арасында һәр дератизация эшкәртүеннән соң 30 көн саен нәтиҗәлелек контроле уздырып үткәрергә;

балаларның ял итү оешмалары территориясендә алар ачылганчы 20-25 көн алдан аның тирәли 50 метрлы зонада талпанга каршы эшкәртү уздыру, шулай ук вируслы талпан энцефалиты буенча эпидемик территорияләрдә урнашкан ял итүнең стационар оешмаларында сменалар арасында, ике тапкыр нәтиҗәлелек эффекты белән 3-5 һәм талпанга каршы һәр эшкәртүдән соң 15-20 көн аша;

балаларның коллектив ял итүен оештыручылар балалар коллективларын республикадан читкә җибәрү турындагы планлаштырылган сроклар турында Татарстан Республикасы территориясенә аеруча куркыныч инфекцияләр кертүне, төркемле авырулар барлыкка килүне кисәтү максатында китәргә өч тәүлек кала Татарстан Республикасы буенча кулланучылар хокукын яклау һәм кешеләрнең иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсенә хәбәр итү;

тимер юл, авиация, автомобиль юллары буйлап (юлда өч сәгатьтән артыграк булганда) һәм су транспортында ташу буенча санитар-эпидемиологик таләпләрне үтәү;

ял итү оешмаларына эшкә урнашучы (эшләүче) затларның педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә Россия Федерациясенең Хезмәт кодексының 331 нче маддәсендә каралган каршылыклар булу-булмауга закон нигезендә алдан тикшерүләр уздыру оештыру;

балаларны ташуны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елгы 17 декабрендәге “Балаларны автобуслар белән ташуны оештыру Кагыйдәләрен раслау турында”гы 1177нче Карары белән расланган балаларны автобуслар белән ташуны оештыру Кагыйдәләре нигезендә оештыру;

оештырырга:

талпан энцефалитын, боррелиозны һәм бөер синдромы белән геморрагик бизгәк авыруларын кисәтү максатында биналарга һәм территорияләргә (шул исәптән файдаланылмаучыларга да) дымлы профилактик дезинфекция, десинсекция и дератизацияләр үткәрү, әлеге эшләрне башкарырга хокукы булган аккредитация узган оешмалар белән муниципаль контрактлар (килешүләр) төзеп;

лагерьны ачу һәм ябу алдыннан аның тирәли 500 метрлы зонада дератизация уздырырга, алдан энтомологик бәяләү белән лагерь территориясеннән 50 метрдан да ким булмаган арада талпанга каршы (акарицидлы) эшкәртү үткәрү; дератизацион эшкәртүләрнең нәтиҗәлелегенә контроль башкарылган эшләрдән соң 30 көн аша;

талпанга каршы (акарицидлы) эшкәртүләрнең нәтиҗәлелегенә контроль башкарылган эшләрдән соң өч-биш көн һәм 15-20 көн аша;

янгын-техник минимум программалар буенча балаларның ял итү оешмаларының җитәкче-педагогик составын укыту һәм барлык хезмәткәрләрне гигиеник әзерләү билгеләнгән тәртиптә һәм аларга ел саен аттестация үткәрелә;

эпидемиологик тиф һәм педикулезны кисәтү максатында урын-җир кирәк-яракларын, әйберләрне дезинфекцияләү ял итү оешмалары ачылганчыга кадәр билгеләнгән тәртиптә аккредитация узган оешмалар белән килешүләр төзү чаралары белән;

палата тибындагы лагерьларны талпан вирусы энцефалиты буенча эпидемия булмаган территориядә урнаштыру;

3. “Чистай үзәк район дәваханәсе” сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесенә (Р.Р.Мостафин) тәкъдим итәргә:

дүрт яшьтән унҗиде яшькә кадәрге, хроник авырулары булган, шул исәптән авыр тормыш хәлендә калган балаларны «Детская» (озатуларсыз) яки «Мать и дитя» (ата-аналарның берсе яки законлы вәкиле озатуында) юлламалары буенча санитар дәвалауны оештырырга;

«Детская» юлламасы буенча 30 яшькә кадәрге йөкле хатын-кызларны (санатор-курот дәвалануына мохтаҗ булган) санатор дәвалануга җибәрү, үткәрелгән медицина әйләнеше белән санаториядә булу срогын кыскартып;
учредительләр соравы нигезендә лагерьларны контракт нигезендә медицина кадрлары белән тәэмин итү;

балигъ булмаганнарның укудан буш вакытларында һәм каникуллар чорында аларны вакытлыча эшкә урнаштырганда, шулай ук балалар белән бергә ял итү оешмаларында ял итүче ата-аналарның бушлай медицина караулары узуларын тәэмин итәргә;

ял итү оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналны сезонлы карауларны тәэмин итәргә, Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчадан түләүләр алмыйча, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрының 12.04.2011елгы “Зарарлы һәм (яки) куркыныч производство факторлары һәм эшләр исемлеген, хезмәтнең зарарлы һәм (яки) куркыныч шартлары белән авыр эшләрдә мәшгуль булган хезмәткәрләрне аларны башкарганда мәҗбүри алдан һәм периодик медицина тикшеренүләре уздыру тәртибен раслау турында”гы 302-н номерлы боерыгы нигезендә;

ял итү оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналны сезонлы караулар кысаларында бушлай флюорография тикшеренүен тәэмин итәргә;

ЕГИССОның санатор-курорт оешмаларына юлламалар алган авыр тормыш хәлендә калган балалар турында мәгълүмат бирү буенча эшне тәэмин итәргә.

4. “Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУнә (Купцова О.В.) билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

республикадагы һөнәри сменаларга җибәрелүче балалар өчен юлламалар алуга контрактлар төзү;

Чистай муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча бүлегенә Чистай муниципаль районы башкарма комитетының спорт бүлеге белән берлектә республика, Бөтенроссия халыкара конкурсларда, ярышларда һәм олимпиадаларда, җиңүче һәм призер балалар өчен, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүче, опекун һәм асрауга алган гаиләләрдә тәрбияләнүче, кадет мәктәпләрендә тәрбияләнүче балалар, балалар җәмәгать берләшмәләре әгъзалары өчен оештырылган республикада һөнәри сменаларына, Краснодар өлкәсе һәм Кырым Республикасы территориясендә урнашкан (алга таба –Кара диңгез яр буе) лагерьларга җибәрү өчен укуда, балалар иҗатында, спортта ирешкән уңышлары һәм балалар һәм яшьләр хәрәкәтендә актив катнашканнары өчен закон нигезендә үткәрелүче сатулар нәтиҗәләре буенча бүләкләү сыйфатында, сайлап алу һәм комплектлау;

балаларның дәүләт белем бирү оешмаларында тәрбияләнүче ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар

һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар оешмаларының үз лагерьларында, шулай ук закон нигезендә оештырыла торган сатулар буенча билгеләнгән оешмалар лагерьларында ( тәрбияләнүчеләрнең ялын оештыру өчен бүлеп бирелгән акча хисабына ял итү урынына бару һәм кайту, иминиятләү һәм туклану буенча чыгымнарны кертеп) ял итүен оештырырга;

Чистай муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучы ятим-балаларның ялын оештырырга;

Чистай муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча бүлеге белән берлектә белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган лагерьларда укучыларның ялын оештыру мониторингы һәм методик озату;

белем бирү оешмалары белән берлектә практика үтү чорына студентларны лагерьларда эшләүгә җәлеп итү;

инвалид балаларның һәм хроник авырулары булган балаларның ялын оештырганда педагог –дефектолог белгечләрне ял итү оешмаларында эшләүгә җәлеп итү;

үз компетентлыгы чикләрендә укучыларның ялын оештыруны гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында укучы физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ялын оештыру;

ял итү оешмаларына эшкә җибәрелүче педагогик кадрларны өстәмә белем бирүнең “Республиканың мәктәптән тыш эшләр үзәге” дәүләт бюджет учреждениесе базасында һәм “Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУсе соравы буенча педагогик профильдәге дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында укыту;

5. “Чистай участок урман хуҗалыгының Кама урман хуҗалыгы” ГКУнә (Гыйлметдинов Р.Ф.) балаларның ялын оештыру оешмаларын урман хуҗалыгын, урман паркларын урман хуҗалыгы регламентына кертүгә һәм Россия Федерациясенең Җир кодексы таләпләре нигезендә җир участокларыннан даими (сроксыз) файдалану килешүе төзүдә ярдәм күрсәтергә;

6. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча бүлегенә (Волкова Л.А.) һәм Чистай муниципаль районы башкарма комитетының спорт бүлегенә (Толоконников В.С.) үз компетентлылыкларында оештыруны тәэмин итәргә:

оешма, шул исәптән Кара диңгез яр буе лагерьларында закон нигезендә Чистай муниципаль районы балаларының ялын оештыру буенча үткәрелә торган сатулар нәтиҗәләре буенча билгеләнүче профильле сменаларда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру;

балаларның ял итү оешмаларында профильле сменалар;

физкультура- сәламәтләндерү чаралары;

балансларында лагерь булган оешмалар хезмәткәрләре балаларының ялы;

яшүсмерләрне хәрби-патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән профильле сменалар, чаралар;

авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялы;

җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән ким булган гаиләләрдәге балаларны, социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ булган балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүчеләрне; социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларны, яшьләр һәм балаларның җәмәгать берләшмәләре әгъзаларын, җиде яшьтән 30 яшькә кадәр (30 яшьне дә кертеп) булган халыкара, төбәкара, республика спорт чараларында җиңүчеләрне тернәкләндерүче дәвалау;
студентларның хезмәт отрядлары эше;
Чистай муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең дәүләт ял итү оешмаларын үстерү һәм матди-техник базаны камилләштерү буенча эшләр;

балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга ел саен Татарстан Республикасы бюджетыннан Чистай муниципаль районы бюджетына субсидия бүлеп бирү турында килешү төзү буенча эшләр;

ел саен 15 майга кадәр Россия Федерациясенең Гражданнар оборонасы эшләре буенча министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Гадәттән тыш хәлләр һәм стихияле бәхетсезлекләрне бетерү буенча баш идарәсенә, Татарстан Республикасы (Татарстан) кулланучылар хокукларын яклау һәм кешеләр иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсенә җәйге сезонда эшләячәк Чистай муниципаль районы териториясендә урнашкан балаларның һәм яшьләрнең ял итү оешмалары исемлеген бирергә ( исеме, урнашу урыны адресы, нинди ведомствога каравы);

ЕГИССОга Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы карамагындагы ял итү оешмаларына профильле сменага юлламалар алган балалар турында мәгълүмат бирү буенча эшне тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасының Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Чистай муниципаль районындагы халыкны социаль яклау бүлегенә (Каюмова Г.Р.) Чистай муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча бүлегенә җан башына уртача керем күләме яшәү минимумы күләменнән ким булган гаиләләрдәге, социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ булган балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүче һәм социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балалар турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

8. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлегенә (Ларионова Н.В.) билгеләнгән тәртиптә Чистай муниципаль районында профильле сменалар, Чистай муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган шәһәр янындагы лагерьларга күчмә китапханәләр комплектлауны тәэмин итәргә.

9. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының муниципаль заказлар бүлегенә (Емельянов В.М.) балалар һәм яшьләрнең ялы белән бәйле контрактлар реестрына кертү өчен җибәрелгән килешүләрне аларны алганнан соң өч көнлек срокта карауны тәэмин итәргә.

10. Чистай муниципаль районы Советының җәмәгать оешмалары, масса-күләм мәгълүмат чаралары белән эшләү һәм милләтара мөнәсәбәтләр бүлегенә (Хөснуллин Р.Н.) масса-күләм мәгълүмат чараларында балаларның һәм

яшьләрнең ялын оештыру буенча уңай эш тәҗрибәсен һәм әлеге өлкәдәге аеруча актуаль проблемаларны яктыртуны тәэмин итәргә.

11. Чистай муниципаль районы башкарма комитетына һәм балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы милекнең барлык төрләре белән дә эшләүче оешмаларга тәкъдим итәргә:

балаларның һәм яшьләрнең ял итү оешмаларында ял итүче балаларның суда коенулары өчен билгеләнгән су объектларының төбен чистартуны вололазлар тикшерүен тәэмин итәргә;

балаларның һәм яшьләрнең ял итү оешмаларында эшләүгә медицина персоналын кабул итүнең килешү формасын карарга;

балаларның һәм яшьләрнең ял итү оешмаларында булу вакыты һәм анда бару чорында балаларны һәм яшьләрне бәхетсезлек очракларыннан ирекле иминиятләүне тормышка ашыруны оештырырга;

төзелгән килешүләр, дәүләт һәм муниципаль контрактлар нигезендә килешүләр, дәүләт һәм муниципаль контрактлар белән каралган срокларда Татарстан Республикасы бюджеты акчасын файдалану турындагы отчетны үзвакытында тапшыруны тәэмин итәргә;

үз компетентлыгы чикләрендә балалар һәм яшьләрнең дәүләтнеке булмаган ял итү оешмалары территорияләрен, җәмәгать тәртибен иминлекне шәхси сак оешмалары белән саклауга юнәлдерелгән чаралар кабул итәргә.

12. Тәкъдим итәргә:

12.1. Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Роспотребнадзор идарәсенең Чистай районындагы һәм Чистай шәһәрендәге территориаль бүлегенә (Хәйруллина Ф.С.) акча түләмичә генә түбәндәгеләрне үткәрүне тәэмин итәргә:

ял итү оешмаларының гамәлдәге санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә тәңгәл килүенә санитар-эпидемиологик экспертиза;

ял итү оешмаларына эшкә җибәрелүче персоналны профилактик медицина караулары һәм гигиеник укытулар, аларны ачар алдыннан лаборатор-инструменталь тикшеренүләр, шулай ук гельминтозларга ( тизәктә паразитлар, лямбийләр булу-булмауга һ.б.анализ), эчәк инфекциясе барлыкка китерүне йөртүгә, корсак тифына канны серологик тикшерүләр;

укудан буш вакытта һәм каникуллар чорында балигъ булмаганнарны вакытлыча мәшгульлеккә рәсмиләштергәндә медицина караулары;

дәүләт заданиеләре кысаларында Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Чистай районындагы һәм Чистай шәһәрендәге территориаль бүлеге күрсәтмәләре нигезендә сәламәтләндерү оешмаларын ачар алдыннан дератизацион һәм акарицидлы эшкәртүләрнең нәтиҗәлелегенә контроль;

ЕГИССОга юлламалар алган авыр тормыш хәлендә калган балалар, муниципаль һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары, коммерцияви һәм коммерцияви булмаган оешмалар хезмәткәрләре (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан кала) балалары һәм мәгариф оешмалары тарафыннан оештырылган ял һәм хезмәт лагерьларында көндез булу белән ял иткән балалар турында мәгълүмат бирү буенча эшне тәэмин итәргә;

12.2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр буенча министрлыгының Чистай муниципаль районы буенча идарәсенә (Манов С.А.) ял итү оешмаларында янгын иминлеге таләпләрен үтәүгә күзәтчелек итүне һәм оештырылган коену урыннарында техник тикшереп чыгуны тәэмин итәргә.

12.3. Россия Эчке эшләр бүлегенең Чистай районы буенча бүлегенә (Денисов О.Г.) закон нигезендә балаларны лагерьларга оештырылган алып баруны һәм алып кайтуны башкаручы транспорпт чараларын озата баруны тәэмин итәргә.

12.4. Шәһәр башкарма комитетына (Заиконников А.Г.), “Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУнә (Купцова О.В.), Чистай муниципаль районы башкарма комитетының спорт бүлегенә (Толоконников В.С.), Чистай муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлегенә (Ларионова Н.В.), Чистай муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча бүлегенә (Волкова Л.А.) билгеләнгән тәртиптә үз компетентлылыклары чикләрендә тәэмин итәргә:

балаларның ял итү оешмаларының эшләвен;

1 июньнән 30 августка кадәр йорты алды территорияләрендә муниципаль белем бирү оешмалары, яшүсмерләр клублары һәм яшьләр үзәкләре базасында балалар мәйданчыклары эшен;

күпләп-ял итү урыннарына медик-санитар хезмәт күрсәтү һәм иминлекнең ведомство хезмәтләре һәм шәхси сак структуралары белән берлектә җәмәгать тәртибен саклау;

өстәмә белем бирүче муниципаль оешмалар базасында мәгариф системасы лагерьларына эшкә җибәрелүче педагогик кадрларны укыту;

Чистай муниципаль районының белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган лагерьларда балаларның ялын оештыру;

Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгына Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгы һәм Чистай муниципаль районы башкарма комитеты арасында төзелгән икеяклы килешүләр белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетыннан Чистай муниципаль районы бюджетына балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга субсидия бүлеп бирү турында, Чистай мунципаль районы балаларының ял итү оешмаларында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү;

12.5. Нинди милек формасы белән эшләүләренә бәйсез рәвештә оешмалар җитәкчеләренә ялны оештыручыларның, лагерьлар начальникларының һәм аларның тәрбия эше буенча урынбасарларының Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре буенча министрлыгының Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, җирле үзидарә органнары тарафыннан уздырыла торган квалификацияне күтәрү буенча республика конкурсларында катнашуын оештырырга.

13. Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 14.12.2017елгы “Чистай муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында”гы 956 нчы карары үз көчен югалткан дип табарга.

14. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштырырга.

15. Әлеге Карарны үтәүгә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю Задворновага йөкләргә

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов